**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯХШЫЙ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам, 17 нче йорт.
Тел.(885552)3-44-45

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ**
**РАЙОН СОВЕТ ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423765, с. Верхнее Яхшеево, ул. Новая,
дом 17. Тел.(885552) 3-44-45.

E-mail vyah.akt@yandex.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«01» март 2021 ел** **№ 2**

**Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советының 07 сентябрь 2017 ел, № 21 «Югары Яхшый авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советының 07 сентябрь 2017 ел, № 21 « Югары Яхшый авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11.2. бүлек, Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 12 нче абзац белән тулыландырырга:

«12) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Югары Яхшый авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Югары Яхшый авыл җирлеге
Советы Башлыгы Җ. Г. Зиннатуллина